| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.01.25 Казан ш. 189-р

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Салым салу максатларында биналардан (корылмалар, каралтылар) һәм йортлардан фактик файдалану төрен билгеләү турында” 18.11.2024 № 3671-р боерыгына үзгәреш кертү турында

“Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясын, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^1$ статьясын, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 26 июлендәге № 66-ЗРТ Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге № 977 карары белән расланган Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү тәртибен һәм Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.101 пунктына һәм салым салу максатларыннан биналар (каралты, корылма) һәм йортларның фактик куллану төрен билгеләү тәртибен һәм салым салу максатларыннан биналар (каралты, корылма) һәм йортларның фактта

файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссиянең 20.01.2025 № 3 карарына нигезләнеп:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Салым салу максатларында биналардан (корылмалар, каралтылар) һәм йортлардан фактик файдалану төрен билгеләү турында” 18.11.2024 № 3671-р боерыгына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 23.12.2024 № 4248-р боерыгы белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) кушымтага 30 пунктны төшереп калдырып үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru. адреслы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешене контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**